СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 215 от 09.04.2018

на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында

Шәһәр төзелеше өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 29.1-29.4 маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 15 маддәсенең 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2017 елның 07 ноябрендәге 177 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы һәм аның составына кергән авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районның җирле әһәмияттәге сораулары булуын һәм авыл җирлекләре биләмәләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын расларга (теркәлә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ